# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫТАШБИЛГЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 4 марты 2№

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Ташбилге авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә керми торган яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында**

**Россия Федерациясе Урман кодексы ,Россия Федерациясенең 2003 елның 06 октябрендәге"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законы, 2002 елның 10 гыйнварындагы"Әйләнә-тирә мохитне саклау турында" 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендәТатарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Ташбилге авыл җирлеге Советы карар итте:**

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Ташбилге авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә керми торган яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Ташбилге авыл җирлеге башлыгы **Р.Ф.Әхмәдиевка** йөкләргә.

Ташбилге авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Әхмәдиев

Расланган
Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районының Ташбилге авыл җирлеге
Советының 2021 елның 4 мартындагы
2№ карары

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Ташбилге авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә керми торган яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмә**

Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Ташбилге авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә керми торган яшел үсентеләр кисү тәртибен билгели.

1. Төп төшенчәләр

Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

яшел утыртмалар - табигый һәм ясалма үсеп чыккан агач, куак һәм үлән үсемлекләре (паркларны, скверларны, бакчаларны, газоннарны, чәчәклекләрне, шулай ук аерым торучы агачларны һәм куакларны да кертеп);

табигать территорияләре - бердәм географик (климат) шартларында формалашкан җирлек, туфрак, үсемлекләр рельефының билгеле бер типларын берләштерүче, хуҗалык эшчәнлегенә кагылгысыз яисә аз кагылган территорияләр;

яшелләндерелгән, ясалма булдырылганяшелләндерү объектлары (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш), төрле функциональ билгеләнештәге җирләрнең аз булдырылганучастоклары, алар чикләрендә өслекнең 50 проценттан да ким булмаган өлешен үсемлекләр капламы биләп тора;

урман территорияләре-табигый барлыкка килгән урман үсемлекләре белән капланган төрле функциональ билгеләнештәге табигый территория участоклары;

агач-үсентеләрдән тыш 1,3 м биеклектә, 5 см диаметрдан да ким булмаган үсемлек;

куак - туфрак өслегендә тармакланган күпьеллык күптармаклы (агачтан аермалы буларак) үсемлек;

үлән капламы - газон, табигый үлән капламы;

ешлык - нинди дә булса урында куе үсә торган үсемлекләр, куаклар;

яшел массив - бердәм каплам ясаучы карт (15 яшьтән өлкәнрәк) кимендә 50 төп агач үсә торган территория участогы;

яшел үсентеләргә зыян китерү - аларның үсешен туктату, шул исәптән ботакларга, тамыр системасына механик зыян китерү, тамырның бөтенлеген, тере туфрак катламын бозу, яшел үсентеләрне яисә тамыр зонасындагы туфракны зарарлы матдәләр белән пычрату, ут төртү яки башка йогынты ясау;

яшел үсентеләрне юк итү (югалту) - яшел үсентеләрнең үсешен туктатуга китерә торган кисү яки башка зыян китерү;

компенсацион яшелләндерү - юк ителгән яки 2 коэффициентзарарланган яшел утыртмаларны яңадан утырту.

## 2. Яшел үсентеләрне саклауның төп принциплары

Авыл җирлеге территориясендә үсә торган яшел үсентеләр саклагыч, рекреацион, эстетик функцияләр башкара һәм сакланырга тиеш.

2.1.Авыл җирлеге территориясендә (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) урнашкан барлык яшел үсентеләр (агачлар, куаклар) сакланырга тиеш.

2.2.Авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләрнең сакланышын һәм үсешен тәэмин итү буенча бурычлар йөкләнә:

2.2.1.оешмаларга эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән кишәрлекләрдә - әлеге оешмалар җитәкчеләренә;

2.2.2.милектәге яки арендадагы участокларда - юридик затларга һәм гражданнарга - милекчеләр яки арендаторларга.

2.3.Яшел утыртмалар урнашкан җир кишәрлекләренең милекчеләре, файдаланучылары һәм арендаторлары яшел утыртмаларның сакланышын, яшел утыртмаларны тиешенчә карауны тәэмин итәргә тиеш.

2.4.Әлеге Нигезләмә авыл җирлеге территориясендә милек формасына карамастан, авыл җирлеге территориясендә агач-куак кисүгә бәйле проектлау, төзелеш, ремонт һәм башка эшләр алып баручы барлык гражданнарга һәм оешмаларга кагыла.

2.5.Авыл җирлеге территориясендә хуҗалык, шәһәр төзелеше һәм башка эшчәнлек Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән яшел үсентеләрне саклау таләпләрен үтәп башкарыла.

2.6.Җир кишәрлеген сайлау акты, төзелеш, хуҗалык һәм башка эшчәнлекне оештыруга проект алды һәм проект документациясендә яшел утыртмаларның торышы турында тулы һәм дөрес белешмәләр һәм проектлана торган объектның яшел утыртмаларга йогынтысын тулысынча бәяләү булырга тиеш.

2.7.Яшелләндерелгән территорияләрдән һәм яшел массивлардан яшел үсентеләрнең тереклек эшчәнлеген тәэмин итүгә туры килми торган файдалану рөхсәт ителми.

3. Яшел утыртмаларны (агачларны, куакларны) кисү тәртибе.

3.1.Авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләрне рөхсәтсез кисү тыела.

3.2.Авыл җирлеге территориясендә агач һәм куакларны кисү рөхсәт нигезендә башкарыла.

3.3.Рөхсәт бирү мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычы булмаган очракта гамәлгә ашырыла.

3.4.Яшел үсентеләрне кисү эшләре билгеләнгән нормаларга һәм кагыйдәләргә туры китереп, мөрәҗәгать итүче акчасы хисабына башкарыла. Агач кисү бары тик аттестацияләнгән белгечләргә генә рөхсәт ителә.

3.5.Киселгән яшел үсентеләрне һәм киселгән калдыкларны кисү, төяү, төяү һәм чыгару эшләремөрәҗәгать итүче хисабына башланган көннән өч көн эчендә башкарыла. Киселгән яшел үсентеләрне һәм киселгән калдыкларны эш урынында саклау тыела.

3.6.Территориянең кисү урынына газон, яшел үсентеләр зарарланган очракта, үз компетенцияләре чикләрендә территория хуҗасы һәм контроль органнары белән килешенгәнэшне башкаручы, зыян килгән вакыттан ярты елдан да соңга калмыйча, аларны мәҗбүри рәвештә торгызу эшләрен башкара.

3.7.Агачны кискән өчен түләмичә агач һәм куакларны кисү авыл җирлегенең башкарма комитеты тарафыннан түбәндәге очракларда рөхсәт ителергә мөмкин:

яшел үсентеләрне тәрбияләү, санитар кисүләр һәм реконструкцияләү;

авария хәлендәге һәм башка гадәттән тыш хәлләрне бетерү, шул исәптән җир асты коммуникацияләрен һәм капиталь инженерлык корылмаларын ремонтлау;

Дәүләт санэпидемнадзор бәяләмәсе булса, торак һәм иҗтимагый биналарда яктылыкны каплый торган агач һәм куакларны кисү;

Авария хәлендәге (аву куркынычы тудыручы, коры-сары) агачларны һәм куакларны кисү.

Югарыда күрсәтелгән очракларда яшел үсентеләр кисүне гамәлгә ашыручы мөрәҗәгать итүчегә авыл җирлеге башкарма комитеты белән килештерелгән урыннарда компенсацияле яшелләндерүне үткәрергә кирәк.

3.8.Авария, коры-сары һәм куркыныч тудыручы яшел үсентеләр комиссия тикшерүе нигезендә киселә.

3.9.Яшел үсентеләрне санкциясез кисү яки юк итү дип таныла:

агачлар һәм куаклар рөхсәтсез кисү,рөхсәт буенча, ләкин рөхсәттә күрсәтелгән участокта, санда һәм токымны кисмәү;

ут төртү яки ут белән саксыз эш итү нәтиҗәсендә агач һәм куакларны юк итү яки зыян китерү;

кәүсәне бождралауяки уемлау;

үсә торган агач һәм куакларның үсеш туктатылганчыга кадәр зарарлануы;

агач һәм куакларның агым су, химик матдәләр, калдыклар һәм башкалар белән зарарлануы;

корыган агачларны рөхсәтсез кисү;

үсүче агач һәм куакларның башка зарарланулары.

## 4. Компенсацион яшелләндерү.

4.1.Компенсацион яшелләндерү рөхсәт ителгән агач кисү, законсыз рәвештә яшел үсентеләрне зарарлау яки юк итү очракларында гамәлгә ашырыла.Компенсацион яшелләндерү агачлар, куаклар һәм газоннар утырту өчен туры килә торган вакытта, әмма яшел үсентеләрне зарарлау яки юк итү факты ачыкланганнан соң бер елдан да соңга калмыйча башкарыла.

4.2.Компенсацион яшелләндерү мәнфәгатьләрендә яки хокукка каршы гамәлләре нәтиҗәсендә яшел үсентеләрне зарарлау яки юк итү булганграждaннар яисә юридик затлар акчалары исәбеннән башкарыла.

4.3.Әлеге Нигезләмә нигезендәяшел утыртмаларга китерелгән зыян натураль формада,компенсацион яшелләндерү белән капланырга тиеш:2 коэффицент белән юкка чыгарылган урынына яшел утыртмаларны утырту.

## 5. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда яшел утыртмаларны саклау

5.1.Авыл җирлегендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру яшел үсентеләрне саклау таләпләрен үтәү белән алып барыла.

5.2.Яшелләндерелгән территорияләр, шул исәптән яшел массивлар, шулай ук яшелләндерелгән территорияләрне үстерү өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре аларның максатчан билгеләнешенә бәйле булмаган төзелештә кулланылырга тиеш түгел.

5.3.Яшел үсентеләр биләгән җир кишәрлекләрендә төзелешне оештырганда, проект документларында киселергә тиешле яшел үсентеләрне бәяләү булырга тиеш.Бу очракларда зыянны каплау әлеге Нигезләмәнең 2 һәм 3 бүлекләрендә билгеләнгән тәртиптә агач киселгән өчен түләүне алдан кертү һәм компенсация яшелләндерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 6. Эшмәкәрлек эшчәнлеген тормышка ашырганда яшел үсентеләрне саклау.

6.1.Авыл җирлеге Башкарма комитеты рөхсәтеннән башка яшелләндерелгән территорияләрдә һәм яшел массивларда сәүдә һәм башка эшмәкәрлек эшчәнлеге алып бару, палаткалар һәм башка корылмалар урнаштыру тыела.

6.2.яшелләндерелгән территорияләрдә һәм яшел массивларда эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыргандашартлау куркынычы , янгын куркынычы булган һәм агулы матдәләрне файдалану,территорияне пычрату һәм чүпләү, яшел утыртмаларның зарарлануына яки юкка чыгуына китерергә сәләтле башка эшләртыела.

## 7. Административ җаваплылык.

7.1.Әлеге Нигезләмәне үтәмәүдә гаепле затлар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплы.